**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге составына керүче Норлат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре карары**

12 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «2021 елда Норлат авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия Норлат авыл җирлегендә яшәүче һәр балигъ булмаган һәр баладан 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм Норлат авылында Үзәк урамы буенча ял итү зонасын төзекләндерү өчен алынган акча белән килешәсезме?» - дигән сорау буенча 2020 елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучы 223 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 184 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 176 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 8 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге составына керүче Норлат авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «2021 елда Норлат авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия Норлат авыл җирлегендә яшәүче һәр балигъ булмаган һәр баладан 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм Норлат авылында Үзәк урамы буенча ял итү зонасын төзекләндерү өчен алынган акча белән килешәсезме?»-дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Норлат авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ М.Х. Закиров

Норлат авыл җирлеге
башлыгы __________ М.Х. Закиров